## АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МЮД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

**№ 15** **19 гыйнвар 2016ел**

**Мюд авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымнарын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү һәм үткәрү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, “Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Мюд авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 15 статьясына нигезләнеп Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советы КАРАР кылды:

"1. Мюд авыл җирлеге Советының инициативасын хупларга һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге территориясендә 2016 елның 6 мартында якшәмбедән 7.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне раслау:

**«Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Мюд авыл җирлеге территориясендә, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның 1 төркеме һәм 1 төркем инвалидларыннан тыш, 2016 елдан башлап даими 300 сум күләмендә,теркәлгән һәр кешегә, шулай ук теркәлүе булмаган, әмма милке булган кешегә 2016 елдан башлап, үзара салым акчаларының ел саен бер тапкыр түләнә торган түләүләрен кертүгә сез килешәсезме?»**

- Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
- 
- **1. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итү.**
- *** Иске Мокшино авылы–яңа су башнясы кую 20 000 сум.**
- *** Иске Мокшино авылы - яңа сууткәргеч трассасы салу 26 600 сум.**
- **Пионер – скважинаны ремонтлау 31 100 сум.**
- **1. Авыл җирлеге чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге.**

*** Татар Сөнчәле авылы-торак пункт эчендә вак таш җәелгән юл катламын урнаштыру-144500 сум.**
*** Татар Сөнчәле авылы-Олы Сөлчә елгасы аша күперне ремонтлау-51 100 сум.**
*** Әхмәт авылы-Әхмәт авылына кадәр вак таш түшәлгән юл катламын урнаштыру - 15 300 сум.**
**1. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру.**
*** Мюд п. – буаны чистарту-45000 сум.**

«РИЗА» «КАРШЫ».

3.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге территориясе чикләрендә референдум түгәрәген билгеләргә.

4.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге башкарма комитетына 18 яше тулган сайлаучылар исемлеген төзергә һәм раслау өчен мюд авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләренә тапшырырга.\

5.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләренә гамәлдәге законнар нигезендә Мюд авыл җирлеге территориясендә референдум үткәрүне оештырырга.

6.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://Aksubayevo.tatarstan.ru һәм мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча халыкка җиткерергә:

-ТР, Аксубай районы, МЮД поселогы, Үзәк урамы, 27;

- ТР, Аксубай районы, Иске Мокшино авылы, Зеленая ур., 1;

- ТР Аксубай районы, Татар Сөнчәле авылы, Тукай ур., 12

-ТР, Аксубай районы, Пионер п., Үзәк ур., 1

Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге
Совет Рәисе: Н.В. Бокарева